ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.05.2025 п.г.т. Алексеевское № 184

**Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 30.12.2022 ел, № 585 «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 24.11.2020 ел, №3081-р боерыгына, «Физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасына (комплекслы программасы), «2019-2026 елларга Татарстан Республикасында физик культураны һәм спортны үстерү» дәүләт программасына тәңгәл рәвештә

**карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 30.12.2022 ел, № 585 «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү чараларының 1 пунктына 1.16 - 1.18. пунктчаларын әлеге карарга кушымта (кушымта) нигезендә өстәргә.

1.2. Карарга кушымтаның «Программаның төп максатлары һәм бурычлары» пунктының «Бурычлар» пунктчасына түбәндәге эчтәлекле яңа абзацлар өстәргә:

- заманча спорт төрләрен үстерү программаларын (шул исәптән компьютер спорты, авиамодель спорты, фиджитал спорт, спорт программалаштыруы һ. б.) формалаштыру һәм аларны спорт төрләрен үстерүнең гомуми системасына интеграцияләү;

- спортның инновацион төрләрен үстерү (компьютер спорты, авиамодель спорты, фиджитал спорт, спорт программалаштыруы һ. б.);

- адаптив физик культура һәм спорт чараларын һәм методларын кулланып, махсус хәрби операция ветераннарын реабилитацияләү, социализацияләү һәм һөнәри үзбилгеләнү өчен шартлар тудыру.

2. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында һәм Интернет челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е. А. Хәмзинага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О. Н. Леденцов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль
районы
Башкарма комитетының
07.05.2025 ел, № 184
карарына кушымта

**2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү чаралары**

| № | Чара эчтәлеге | башкару чоры | башкару өчен җаваплылар |
|---|---|---|---|
| **1. Организационные мероприятия** | | | |
| 1.16 | Заманча спорт төрләрен үстерү программаларын (шул исәптән компьютер спорты, авиамодель спорты, фиджитал спорт, спорт программалаштыруы һ. б.) формалаштыру һәм аларны спорт төрләрен үстерүнең гомуми системасына интеграцияләү | 2023-2025 ел | ЯЭСТ һәм ББПБ, ББ |
| 1.17 | Спортның инновацион төрләрен үстерү (компьютер спорты, авиамодель спорты, фиджитал спорт, спорт программалаштыруы һ. б.) | 2023-2025 ел | ЯЭСТ һәм ББПБ, ББ |
| 1.18 | Адаптив физик культура һәм спорт чараларын һәм ысулларын кулланып, махсус хәрби операция ветераннарын реабилитацияләү, социализацияләү һәм һөнәри үзбилгеләнү өчен шартлар тудыру | 2023-2025 ел | РС, БК, АҖ БК , ҮРХ, СЯБ, ББ, ЯЭСТ һәм ББПБ |

**Башкарма комитетның эшләр идарәчесе** **Г.Ә.Йосыпова**